МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

“Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе”

мәктәпкәчә төркеме

Раслыйм:

Мәктәп директоры:

_______Р.Г.Ахметбаева

Приказ№36 18.08.2021 ел

# Белем һәм тәрбия бирү буенча
# зурлар төркененең
# 2021-2022 уку елына
# комплекслы тематик планы.

Төзүче:

Ахмадуллина Альфинур Закаровна

Беренче квалификацион категорияле тәәәрбияче.

Педагогик киңәшмә утырышында кабул ителде

Беркетмә №2 17 .08.2021 ел.

| Вакыты | Проект темасы. Максаты | Тормышка ашыру чарасы |
|---|---|---|
| 03.09. - 07.09. | **“Минем бакчам”.**<br>1. Бакчага карата ярату хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларга үзләре йөри торган бакча турында төшенчә бирү, белемнәрен камилләштерү.<br>3. “Минем бакчам” дигән темага хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү, үстерешле диалогта катнашу теләге тудыру.<br>4. Балаларның уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү.<br>5. Балаларда бакчага карата ярату хисләре тәрбияләү. | 1. **ФЭМП**. Бер һәм ике, ике һәм өч саннарының барлыкка килүе һәм аларны чагыштыру. Иң биек, тәбәнәгрәк, иң тәбәнәк.<br>Максат: Балаларда математик үзлекләр һәм мөнәсәбәтләр турында күзаллауларны формалаштыруны дәвам итү. Ике һәм өч саннарының барлыкка килү юлларын искә төшерү. Бер һәм ике, ике һәм өч предметлары булган төркемнәрне аерырга өйрәтү, шуның нигезендә кайсы санның зуррак, кайсының кечерәк икәнен аңлату. Предметларны биш саны кысаларында санау күнекмәсен булдыру. Өч предметны аларның биеклегенә карап чагыштырырга өйрәтү: иң биек, биегрәк.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Балалар бакчасы буйлап сәяхәт. Максат: Балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү, балаларга үзләре йөргән бакча турында төшенчә бирү, белемнәрен камилләштерү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү**. Рәсем карау һәм хикәя төзү:”Балалар бакчасында”. Максат: Тәрбияче хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү, тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү. Тәрбияче биргән план ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** М.Фәйзуллина “Өлкән группага күчкәч”. Максат: Балаларның хәтер сәләтен үстерү, шигырьгә кызыксыну уяту һәм ятлау теләге тудыру, һәр эшне вакытында эшләү кирәклеге турында аңлату.<br>5. **Рәсем**. “Тәлинкәдә алмалар.”. Максат: Балаларны алмаларга хас билгеләрнең сортларына бәйле булуын төшенүгә этәрү. Гуашь буяулар белән эшләү күнекмәләрен ныгыту. Нәфасәти кабул итүне үстерү: балалар игътибарын форма һәм төсләр кушылмасы гүзәллегенә юнәлтү.<br>6. **Рәсем.** Күңелле җәй. Максат: гади генә сюжетны һәм персонажларның хәрәкәтен рәсемдә күрсәтә белергә өйрәтү. |

| | | |
|---|---|---|
| 10.09. - 14.09. | **Мин яратам сине, Татарстан.**<br>1. Балаларда туган якка тугърылык, ярату хисләре тәрбияләү.<br>2. Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә сүз байлыгын арттыру, активлаштыру, диалогик сөйләмне үстерү.<br>3. Балаларның туган ил турындагы күзаллауларын киңәйтү, “кече илгә” карата кызыксыну формалаштыру.<br>4. Татарстан башкаласы Казан турында белемнәрен тирәнәйтү. Татарстан символикасы һәм аның мәгънәсе белән таныштыру.<br>5. Яшәгән җирен Татарстан дип өйрәтү, аның күпмилләтле республика булуы, шәһәр һәм авылларның күплеге турында күзаллау формалаштыру. | 1. **ФЭМП.** Өч һәм дүрт саннарының барлыкка килүе һәм аларны чагыштыру. Озын, кыска, тар. Максат: Балаларга өч һәм дүрт саннарының барлыкка килүен, оешуын искә төшерү, предметларны санарга һәм санап алырга өйрәтү, предметларны озынлык, киңлек һәм калынлыкларына карап чагыштыру күнегүләрен үтәү. Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын, дәлилле сөйләмне, игътибарлылыкны, мөстәкыйльлекне үстерү<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Туган ил кайдан башлана. Максат: Балаларда туган якка карата ярату хисләре тәрбияләү. Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә сүз байлыгын арттыру, активлаштыру, диалогик сөйләмне үстерү.<br>3. **Рәсем**: Каен һәм имән. Максат: агачларга хас билгеләрне чагыштырырга һәм төрле өлешләрен, пропорцияләрен күрсәтеп сурәтләргә өйрәтү. Коры өслектә акварель белән эшләү техникасын аңлату. Туган як үсемлекләре гүзәллеген күрә белергә өйрәтеп, балаларның нәфасәти хисләрен үстерү.<br>4. **Рәсем**. Менә җәй дә үтеп китте. Максат: җәйнең төсләрен чагылдыру, җәйге палитраны төзү.<br>5. **Сөйләм телен үстерү**. Башкалабыз – Казан. Максат: туган якка мәхәббәт тәрбияләү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү, Татарстан башкаласы Казан турындагы белемнәрен тирәнәйтү.<br>6. **Сөйләм телен үстерү**. Р.Рәкыйпов “Мин яратам сине, Татарстан!” . Максат: матур әдәбият әсәрләре аша балалар күңелендә туган илне сөю хисе тәрбияләү, балаларның тыңлый белү, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белү сәләтен үстерү, туган як турында белемнәрен системалаштыру. |

| | | |
|---|---|---|
| 17.09.-<br>21.09. | **Яхшы сүз – җан азыгы.**<br>1. Балаларда якыннарына, әти-әниләренә карата кайгыртучанлык, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Әкияттәге образларны дөрес итеп бирә белү, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Әдәби әсәрләр аша тирә-юньдәге вакыйгаларга дөрес бәя бирә белү сыйфатларын камилләштерү.<br>4. Матур әдәбият геройлары аша төрле начар сыйфатларга карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү. | 1. **ФЭМП.** Геометрик фигуралар. Өч һәм дүрт саннарының оешуы. Кычкырып санау. Максат: Төрле геометрик фигураларны аерырга өйрәтү, овал, квадрат өчпочмак, турыпочмаклык, шар, цилиндр, куб, фигураларны, күреп тоемлана торган үрнәк аркылы, капшап табарга өйрәтү, балаларда өч һәм дүрт саннарының оешуы турындагы күзаллауларын ныгыту, тавышлар һәм предметлар саны арасында бәйләнеш урнаштырырга өйрәтүне дәвам итү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Тату уйнау нинди күңелле! Максат:балалар арасында дусларча мөнәсәбәт булдыру, уенчыкларны үзара бүлешеп уйнарга күнектерү, бере-берсе белән матур сөйләшергә кирәклеген төшендерү.<br>**3. Рәсем:** “ Көнбагышлар”. Максат: Сары таҗ яфракларының төрле төсмерләрен, орлыклар белән тулы үзәгенең көрән, кара, соры төсләрен рәсемдә күрсәткәндә, балаларда тҗөс тою сәләтен, нәфасәти кабул итүне үстерү. Көнбагышка хас үзенчәлекле билгеләрне пумала һәм мамык таякчык белән сылап-сылап ясарга өйрәтү.<br>4. **Рәсем:** Түбәтәй. Максат: Декоратив-гамәли сәнгатҗ предметларыбелән таныштыруны дәвам итү. Бизәк элементларын сайлап, аларны дөрес урнаштырып, татар ир-егетләрнең милли баш киемен бизәргә, түгәрәк эченә рәсем төшерергә өйрәтү. Татар милли орнаментын таный һәм элементларын атый белүгә ирешү.<br>5. **Сөйләм телен үстерү.** Өстәл театры “Өч кыз”. Максат: Балаларда якыннарына, әти-әниләренә карата кайгыртучанлык, игүтибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.Әкияттәге образларны дөрес итеп бирә белү, хәтер сәләтен үстерү. Әдәби әсәрләр аша тирә-юнҗдәге вакыйгаларга дөрес бәя бирергә, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү.<br>6. **Сөйләм телен үстерү.** Ә.Бикчәнтәева “Тәмле сүз”. Максат: балаларга әсәрнең эчтәлегенә төшенергә булышу, матур әдәбият геройлары аша төрле начар сыйфатларга тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү. Үзе һәм яшҗтәшләре кылган эшләргә дөрес бәя бирә белү, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, монологик сөйләмне үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 24.09.-28.09. | **Алиш Алиш иҗаты.**<br>1. А.Алиш әсәрләренә кызыксыну уяту, язучы әкиятләре аша балаларда уңай сыйфатлар тәрбияләү.<br>2. Балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.<br>3. А.Алишның тормыш юлын, иҗатын өйрәнү.<br>4. А.Алишның әсәрләренә кызыксыну уяту һәм балаларда сәламәтлекне саклау кебек яхшы сыйфатларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>5. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтару, әсәрнең эчтәлегенә, геройларның эш-гамәленә карата мөнәсәбәтен белдерү һәм аны үз сүзләре белән әйтүләренә ирешү.<br>6. А.Алиш әсәрләре буенча балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү. | 1. **ФЭМП**. Предметларны биш саны чикләрендә санау. Түгәрәк, квадрат, турыпочмаклык. Кәгазь битендә ориентлашу: өстә, аста, сулда, уңда, уртада. Үз-үзеңнән юнәлеш: алда, артта. Максат: биш саны чикләрендә санау күнекмәләрен ныгыту, предмет атамаларын һәм аларның урнашу урыннарын истә калдыру күнегүләрен үтәү.<br>2. **Рәсем**: Яшелчәләр уңышы. Максат: Акварельнең сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыру. Акварель белән эшләү ысулларын өйрәтү. Төп үрнәк формадан аермаларны күрә белүләрен үстерү. Табышмак җавапларын табуларына ирешү.<br>3. **Рәсем** : Алтын көз. Миниатюра жанры белән таныштыру. Дымлы кәгазь битендә акварель буяулар беләнрәсем аша көз төсмерләрен чагылдырырга өйрәтү. Балаларның сүзлек запасын сыйфат сүз төркеме тасвирлары белән баету.<br>4. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** “А.Алиш – балалар язучысы” Максат: А.Алишның тормыш юлы белән таныштыру , әсәрләренә кызыксыну уяту, язучы әкиятләре аша балаларда уңай сыйфатлар тәрбияләү, балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.<br>5. **Сөйләм телен үстерү.** А.Алиш “Каз белән Аккош” хикәясен уку. Максат: А.Алиш әсәрләренә кызыксыну уяту һәм балаларда сәламәтлекне саклау, ныгыту кебек яхшы сыйфатларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. Әсәрнең эчтәлеген аңларга булышу, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>6. **Сөйләм телен үстерү.** А.Алиш “Куян кызы” һәм “Бик яхшы сабак алды Ябалак” әкиятләрен чагыштыру. Максат: әлеге әкиятләрнең уртак якларын табу, язучы әйтергә теләгән фикерне таба белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 1.10.-5.10. | **Хуш киләсең, ямьле көз!**<br>1. Көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксыну хисе тәрбияләү.<br>2. Үзләштергән сүзлек запасына таянып агач, яфрак, үләннәрне, һава торышын тасвирлап сөйли белү осталыкларын үстерү.<br>3. Күзәтүләрдән чыгып, нәтиҗә ясаганда исем ясагыч һәм сыйфат дәрәҗәсен белдерүче кушымчалардан файдаланырга өйрәтү.<br>4. Балаларның бер-берсен тыңлый белү, кирәк урында тулыландыра белү сыйфатларын тәрбияләү.<br>5. Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләргә ярдәм итү.<br>6. Матур әдәбият белән балаларның кызыксынуын үстерү буенча эшне дәвам итү. | 1. **ФЭМП.** Овал. Предметларны аларның үлчәмнәре арта һәм кими бару тәртибендә урнаштыру. Максат:  Балаларны овал белән таныштыру, түгәрәк һәм овалны аеру күнекмәләрен белдерү, предметларны санау күнекмәләрен дәвам итү, предметларны аларның үлчәмнәре арта бару һәм кими бару тәртибендә урнаштыру, иң зур, кечерәк, тангын да кечкенә, әз генә кечкенә, иң кечкенә сүзләрен кулланырга өйрәтү, предметларны капшап санарга өйрәтү. Логик фикерләү, сенсор танып белү ысулларын үстерү – тәртип белән урнаштыру, күзаллау.Математика фәненә ихтирам тәрбияләү, балаларның иҗади кызыксынуын үстерү.<br>2. **Рәсем**  “Көзге келәм” Максат: Традиөион  булмаган сурәтләү материалларын кулланырга өйрәтү. Көз төсмерләрен рәсем аша җиткерү күнекмәләрен ныгыту. Табигатҗ күренешләренә игүтибар итү, күзәтү, алардагы үзгәрешләрне күрү сәләтен үстерү.<br>3. **Рәсем.** “Сыбызгы үрдәк” Максат: Балаларның нәфасәти кабул итү сәләтләрен үстерү. Халык уенчыклары белән кызыксыну уяту. Гомумиләштерелгән кош образын рәсемдә сурәтләү осталыгын камилләштерү. Сыбызгы үрдәк уенчыгын күрсәтеп, балаларның иҗатка омтылышын үстерү.<br>4. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Җәйләр  үтте, көзләр җитте. Максат: балаларда көзге табигатҗнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлык сыйфатлары тәрбияләү. Үзләштерелгән сүзлек запасына таянып агач, яфрак, үләннәрне, һава торышын тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен үстерү.<br>5. **Сөйләм телен үстерү**. Рәсем буенча хикәя төзү. “Көзге табигать” Максат:Балаларда бер-берсен тыңлый белү, кирәк урында тулыландыра белү сыйфатлары тәрбияләү. Балаларның игътибарлылыгын, рәсемдәге детальләрне күрә алу сәләтен үстерү.<br>6. **Сөйләм телен үстерү**. Х.Халиковның “Көз” шигырен ятлау. Максат: балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзтүчәнлек сыйфатлары тәрбияләү. Балаларның хәтер  сәләтен, диалогик сөйләмнәрен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 8.10-<br>.12.10. | **Көз күчтәнәчләре.**<br>1. Балаларда туган як табигатенә, яшелчәләргә карата сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Яшелчәләрне танып белү эшчәнлеген системалаштыру.<br>3. Алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү.<br>4. Матур әдәбият әсәрләренә кызыксынууяту.<br>5. Тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту.<br>6. Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.<br>7. Артистлык сәләтләрен үстерү. | 1. **ФЭМП.** Алты һәм җиде саннарының оешуы. Яссылыктагы юнәлеш: сулдан, уңнан, уртадан. Максат: Биш, алты һәм җиде саннарының оешуын күрсәтү, балаларны җиде саны чигендә хисапларга өйрәтү, предметларның санын хәтердә калдыруны ныгыту, яссылыкта юнәлеш табарга өйрәтү, сулдан, уңнан, уртадан, балаларны урынны билгеләүдә күнектерү: алда, артта, сулда, уңда, алдында, артында. Мөстәкыйльлекне, күзаллауны  үстерү. Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләрне, бер-береңә хәбәр итеп шөгыльләнүне тәрбияләү.<br>2. **Рәсем.** “Алтын хохлома” Максат: Россия халыкларының мәдәни үзенчәлекләрен саклау максатыннан, балаларны декоратив-гамәли сәнгатҗнең үсемлек-чәчәк бизәкләре мотивы белән охшаш яңа төре – хохлома бизәкләре беллән таныштыру.<br>3. **Рәсем.** Е.Чарушинның “Бәбкәләре белән үрдәк” әсәре буенча. Максат: Кошларны төсле таплар ярдәмендә ясарга, аларның үзенчәлекләрен, характерлы торышларын рәсем аша җиткерергә өйрәтүне дәвам итү. Сурәтне кәгазҗ битен тутырып ясауга, акварелҗ буяуларны алдан бераз юешләп эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>4. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Көзге могҗиза. Максат: балаларда туган як табигатенә, яшелчәләргә карата сак караш тәрбияләү. Балаларның иҗади күзаллауларын, күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү. Яшелчәләр турындагы белемнәрен системалаштыру.<br>5. **Сөйләм телен үстерү.** В Хайруллина “Яшелчәләр бәхәсе” әсәрен сәхнәләштерү. Максат: Балаларда матур әдәбият әсәрләренә кызыксыну тәрбияләү. Артистлык сәләтләрен үстерү. Тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту.<br>6. **Сөйләм телен үстерү.**  Шигырь ятлау Х.Гарданов “Түтәлләрдә үсте яшелчә” Максат: Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү, хәтер сәләтен, игътибарлылыгын үстерү, матур әдәбият әсәрен сәнгатьле итеп сөйли белүләренә ирешү. |

| | | |
|---|---|---|
| 15.10. - 19.10. | **Икмәк – яшәү терәге.**<br>1. Икмәкнең һәркемгә кирәклеген төшендерү. Аны авыл эшчәннәре җитештерүен, аларга төрле машиналар ярдәм итүен аңлату.<br>2. Игенче хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату, игенчегә хөрмәт тәрбияләү.<br>3. Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү.<br>4. Балаларның үз фикерен башкаларга ачык, аңлаешлы итеп сөйләп бирү күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтен камилләштерү.<br>5. Халык педагогикасы аша балаларда күңел күтәренкелеге, шатлык хисләре тәрбияләү.<br>6. Игенченең мактаулы һәм авыр хезмәте, икмәкнең нинди юллар аша табынга килүе турында картина буенча тасвирлап сөйләү күнекмәләрен камилләштерү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. | 1. **ФЭМП.** Алты һәм җиде саннарының оешуы. Предметларны җиде саны эчендә санау. Яссылыкта ориентлашу. Максат: Балаларда интеллектуаль-иҗади башлангычларны үстерү, зирәклек, мисалларның стандарт булмаган чишелешен табарга омтылу, аң операцияләре, математик үзлекләрне һәм чагыштырмаларны танып белүнең логик ысуллары: чагыштыру һәм анализ, логик фикерләү, комбинатор сәләтләр.<br>2. **Рәсем.** Е.Чарушинның “Тюпа, Томка һәм саескан” әсәре буенча. Максат: күмернең сурәтләү мөмкинлекләре һәм аның белән эшләү тәртибен аңлату. Хайваннарга хас үзенчәлекләрне һәм аларның торышларын рәсем аша җиткерә белергә өйрәтүне дәвам итү. Әдәби әсәрләргә яңа сурәтләү материалы – күмер белән иллюстрация ясаганда, балаларның образлы күзаллауларын үстерү.<br>3. **Рәсем.** Дымково колынын бизәү. Максат: Яңа кызыклы юллар табып, Дымково бизәкләре элементларын бергә кушарга өйрәтү. Балаларның Дымково уенчыклары, бизәкләре, Дымково уенчык хайваннарын бизәү эзлеклелеге турындагы белемнәрен ныгыту. Россия халыкларының декоратив сәнгате белән кызыксынуларын арттыру.<br>4. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Игенче хезмәте белән танышу. Максат: Балаларда игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. Игенче хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату.<br>5. **Сөйләм телен үстерү**. Әңгәмә “Икмәк – тормышның нигезе”. Максат: икмәккә сак караш тәрбияләү, балаларның хәтерен, фикер йөртә белү сәләтләрен үстерү, икмәкнең әһәмиятен аңлату, ипи үстерүдә катнашучыларның хезмәте турында белемнәрен ныгыту.<br>6. **Сөйләм телен үстерү**. Әкият уку “Икмәк” Төрекмән халык әкияте. Максат: икмәккә сак караш, хөрмәт тәрбияләү, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү, игенче хезмәте турындагы белемнәрен ныгыту, татар халкының хезмәт сөючән халык икәнен, ялкаулыкның начар сыйфат саналуын аңлату. |

| | | |
|---|---|---|
| 22.10.-<br>26.10. | **Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары.**<br>1. Гаилә әгъзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзүләренә ирешү.<br>3. Гаилә белән горурлану хисе тәрбияләү.<br>4. Дөньяда яшәүче башка халыкларга ихтирам, алар турында кызыксыну сыйфатлары тәрбияләү.<br>5. Балаларның фикерләү, күзаллау сәләтен үстерү.<br>6. Җир йөзендә яшәүче халыкларның торак йортлары аларның яшәү урынына бәйле булуы турында аңлату.<br>7. Йорт җиһазларына сакчыл караш, аларны ясаучыларга хөрмәт тәрбияләү.<br>8. Балаларның йорт җиһазлары турындагы белемнәрен баету, тирәнәйтү. | 1. **ФЭМП.** Тавышларны санау. Тәүлек өлешләре. Атна көннәре. Кәгазь битендә орентлашу. Максат: Тәүлек өлешләре турындагы күзаллауны ныгыту, җиде көннең атна төзүен, атнаның һәр көне үз исеме белән йөртүен, җиде көннең һәрвакыт бер тәртиптә килүе турындагы күзаллауларны балаларга ирештерү, кычкырып санарга өйрәтү, тавыш саны һәм күз белән кабул ителгән предметларның саны арасында бәйләнеш урнаштыру күнекмәсен формалаштыру, геометрик фигуралар турындагы белемнәрне һәм кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** "Һәркемнең үз йорты бар. Безнең гаилә". Максат: Балаларда дөньяда яшәүче башка халыкларга ихтирам, алар турында кызыксыну сыйфатлары тәрбияләү. Балаларның фикерләү, күзаллау сәләтен үстерү. Җир йөзендә яшәүче халыклрның торак йортлары аларның яшәү урыннарына бәйле булуын аңлату. Балаларда гаилә әгүзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Ә.Бикчәнтәева "Дәү әнием", Ә.Ерикәй "Әти йорт төзи". Максат: Гаиләңне ярату, дәү әниләргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү. Балаларда әти кешегә карата ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләү. Балаларны шигырьне тыңларга, эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** "Әби-бабайларны хөрмәтлик!" Максат: Зурларга карата хөрмәт тәрбияләү. Куелган сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирү осталыгын үстерү. Әби-бабайларның кадерле кешеләр булуын төшендерү.<br>5. **Рәсем.** Өй күренә тәрәзәдән. Максат: төркем балалары яшәгән урам атамалары белән таныштыру аша балаларда туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү. Балаларны иҗади рәвештә якын килеп, рәсемне тулыландырырга өйрәтү, күзәтүчәнлекләрен арттыру.<br>6. **Рәсем.** Автобус. Максат: Транспортның төп өлешләре, детальләре формасын, пропорцияләрен, урнашу тәртибен рәсем аша җиткерергә өйрәтү. Карандашны төрлечә басып, рәсемне пөхтә итеп буяу осталыгын үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 29.10.-<br>2.11. | **Табын янында.**<br>1. Балаларда савыт-сабага карата сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү.<br>3. Савыт-сабалар кибете турында белемнәрен тулыландыру, тәрбияче үрнәгендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. | 1. **ФЭМП.** Сигез санның оешуы. Сигезгә кадәр санау. Форма. Максат: Балаларны сигез санының оешуы белән таныштыру һәм аларны сигезгә кадәр санарга өйрәтү, төрле зурлыктагы предметларның саны тигезлеген һәм тигез түгеллеген күрә белергә өйрәтү, төрле геометрик фигуралар төзергә өйрәтү осталыгын формалаштыру, зурлык турындагы күзаллауны төгәлләштерү.Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын үстерү, тикшерү, каршы кую, анализ, чагыштыру, абстрактлаштыру, сөйләм, зирәклек, тапкырлык.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Савыт-саба кибетенә сәяхәт. Максат: Балаларда савыт-сабага карата сакчыл караш тәрбияләү. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү. Савыт-саба кибете турында белемнәрен тулыландыру.<br>3. **Сөйләм телен үстерү**. Чагыштырма хикәя төзү. “Чәйнек белән самавыр”. Әңгәмә “Мин кунак яратам”. Максат: Балаларда бер-берсен тыңлый һәм җавапларны тулыландыра белү сыйфаты тәрбияләү.Эзлекле, бәйләнешле итеп чагыштырып тасвирлау хикәясе төзи алу күнекмәләрен камилләштерү. Үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре тәзрбияләү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү**. Ю.Юсупов “Тәлинкәнең төбе нинди”. Максат: Әсәрнең төп идеясын аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирү күнекмәләрен, монологик сөйләмне үстерү.<br>5. **Рәсем**. Безнең авыл урамы. Максат: Балаларда туган авылларына мәхәббәт тәрбияләү, үзләре яшәгән урам атамалары белән таныштыруны дәвам итү. Балаларны вазифаларына бәйле булган корылма үзенчәлекләрен рәсем аша күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү.<br>6. **Рәсем**. Сабый портреты. Максат. Төсле таплардан кеше гәүдәсен ясарга, анын төзелешен, пропорөияләрен рәсем аша җиткерергә өйрәтү, тән төсен күрсәтү өчен, буяуларны кушу. Акварель буяулар белән ясау, палитрадан файдалану күнекмәләрен ныгыту. Сурәтләнә торган предмет һәм әзер эшләрне чагыштырып, балаларның үзләре һәм башка балалар ясаган рәсемнәргә бәя бирү күнекмәләрен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 5.11.-9.11. | **Киемнәр дә безне бизиләр.**<br>1. Балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен үстерү.<br>3. Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү, өс-баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү.<br>4. Халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү.<br>5. Милли киемнәргә кызыксыну уяту. | 1. **ФЭМП.** Сигез саны. Озынлык, биеклек. Максат: Балаларда сигез саны турындагы күзаллауны барлыкка китерү һәм сигез санына кадәр саный белү күнекмәләрен ныгыту. Бер төркем предметларны икенче төркемдәге предметлар белән чагыштырып карап, аларның кайсында предметларның күбрәк булуын ачыкларга өйрәтү, предметларның озынлыкларын һәм биеклекләрен билгеләү, билгеләнгән сан буенча хәрәкәтләр үтәү. Логик фикерләү, хәтер һәм күзаллый белү күнекмәләрен үстерү. Мөстәкыйльлек һәм дөрес итеп тыңлый белүне тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Кием-салым кибете. Максат: балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү.Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү.<br>3. **Рәсем.** Йөк машинасы**.** Максат: Йөк автомобиленең төп өлешләре формаларын, детальләрен, пропорцияләрен, ничек урнашуларын рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү. Балаларның, сурәтне үзләре уйлаганча тулыландырып, машина төзү өчен кирәкле материаллар турында күзаллауларын киңәйтү.<br>4. **Рәсем.** Купшы күлмәк. Максат: Балаларны сарафан формасын рәсемдә күрсәтергә өйрәтү. Сарафан итәгенә, изүләренә рус милли бизәге төшереп, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү. Балаларны дежур торучы вазифаларын мөстәкыйль төстә һәм җиренә җиткереп башкарырга күнектерү.<br>5. **Сөйләм телен үстерү.** Әңгәмә. Милли киемнәр. Максат: халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү, балаларның логик фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү, милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау, төсләрнең берләшүенә игтибар итү.<br>6. **Сөйләм телен үстерү.** |

| | | |
|---|---|---|
| 12.11.-16.11. | **Саулык- зур байлык.**<br>1. Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның үз фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү., сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш тәрбияләү.<br>3. Балаларга сәламәтлекгне саклауда табигатнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру.<br>4. Балаларны гигиена кагыйдәләрен сакларга гадәтләндерү, чисталык – сәламәтлекнең нигезе икәнен төшендерү.<br>5. Матур әдәбият аша балаларда чисталыкка омтылыш тәрбияләү. | 1. **ФЭМП.** Тугыз санының барлыкка килүе. Предметлар санының алар арасындагы ераклыкка бәйле булмавы. Озынлык. Калынлык. Максат: Балаларны тугыз санының барлыкка килүе һәм оешуы белән таныштыру, тугыз саны кысаларында санарга өйрәтү, предметлар санының алар арасындагы ераклыкка бәйле түгеллеген аңлату, предметларның биеклеге һәм калынлыгына карап, аларны үзара чагыштыру, предметларны биеклеге һәм калынлыгына карап, аларны үзара чагыштыру, предметларны биеклеге һәм калынлыгы үсә бару тәртибендә дөресләп тезәргә өйрәтү, чагыштыру төренә карап, предметларны төрлечә урнаштыру мөмкинлеге барлыгын күрсәтү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Су һәм кояш, безнең белән гел юлдаш. Максат: Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү. Балаларга сәламәтлекне саклауда табигатьнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру.<br>3. **Сөйләм телен үстерү**. А.Алиш Куян кызы” әкиятен сәхнәләштерү. Максат: Балаларда матур әдәбиятка кызыксыну, зурлар сүзенә колак сала белү сыйфатлары, сәламәтлеккә сак караш тәрбияләү. Балаларның уйнау осталыкларын, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү**. Ә.Ерикәй “Чисталык сөябез”. Максат: шигырь аша балаларда чисталыкка омтылыш тәрбияләү. Эзлекле һәм сәнгатьле итеп шигырьне сөйләү күнекмәләрен, хәтер сәләтләрен үстерү.<br>5. **Рәсем**. Әкияти йорт. Максат: Әкияти образга хас үзенчәлекләр белзән тулыландырып, бина төзелешен рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтү. Алдан ниятләп куелган эшне ахырына җиткерү зарурлыгын төшендерү. Әзер образга нәфасәти мөнәсәбәт, аны нәфасәти бәяли белү күнекмәләре булдыру.<br>6. **Рәсем**. Көз белән хушлашу. Балаларның ел фасыллары турындагы күзаллауларын баету максатында, рәсем эчтәлеген алдан уйлап куярга өйрәтү. Балаларның, эшчәнлек барышында һәм көндәлек тормышта алган белемнәренә таянып, иҗатка омтылышларын арттыру. |

| | | |
|---|---|---|
| 19.11. - 23.11. | **Исеменә күрә җисеме.**<br>1. Балаларда башка кешеләргә карата игътибар, исемнәргә кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>2. Логик фикерләүне, хәтер сәләтен, хәрәкәт активлыгын үстерү<br>3. Балаларга һәр исемнең аерым бер мәгънә белдерүе турында төшенчә бирү, үзеңнең дә, иптәшләреңнең дә исем-фамилиясен кыскартырга, үзгәртергә, бозарга ярамаганлыгын аңлату. | 1. **ФЭМП.** Тугыз санының оешуы. Биеклек, калынлык . Максат: Балаларда тугыз санының оешуы турында күзаллауны һәм тугыз саны чигендә санау күнекмәләрен ныгыту, ишетеп һәм хәрәкәт нигезендә санауны күнектерү, предметларны биеклек һәм калынлык буенча чагыштыру осталыгын формалаштыруны дәвам итү, аларны биеклеге һәм калынлыгы кимү тәртибендә рәткә салырга өйрәтү. Логик фикерләүне, игътибарлылыкны, хәтерне һәм күзаллауны үстерү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Исемең матур , кемнәр куйган. Максат: Балаларда башка кешеләргә карата игүтибар, исемнәргә кызыксынучанлык тәрбияләү. Логик фикерләүне, хәтер сәләтен үстерү.  Балаларга һәр исемнең аерым бер мәгүнә белдерүе турында төшенчә бирү, үзенең, иптәшләренең дә исем фамилиясен кыскартырга, үзгәртергә, бозарга ярамаганлыгын аңлату.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Без дә хокуклы. Максат: Балаларда уеннар аша бердәмлек, дуслык сыйфатлары, әхлаклылык тәрбияләү. Балаларның кызыксынучанлыкларын, үзләренә, тирә-юнждәгеләргә карата игүтибарлылык, логик фикерләү сәләтен үстерү. Кеше хокуклары турындагы матдәләрне матур әдәбият һәм рәсем-иллюстраөияләр аша балаларга аңлату, белемнәрен ныгыту.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Минем шәҗәрәм. Максат: гаиләләре турында тулы итеп сөйли белергә, сөйләмнәрендә яңа сүзләр кулланырга өйрәтү, балаларда үз нәселең белән кызыксыну уяту, бурыч һәм якыннарына ихтирам хисләре тәрбияләү.<br>5. **Рәсем.** Виноград тәлгәше. Эш барышында төрле материаллар кулланып карау теләге уятып, балаларны яңа иҗади эзләнүләргә этәрү. Образның тәэсир итү көчен рәсем аша биргәндә, төрле төс төсмерләрен файдалану осталыгын ныгыту.  Иҗади күз алдына китерүне үстерү.<br>6. **Рәсем.** Дуслык әйлән-бәйләне. Максат: Милли киемдәге кеше фигурасын, аның гади кул хәрәкәтләрен күрсәтеп рәсем ясарга өйрәтү. Кешенең тән төзелешен, әгзалары формасын һәм зурлыгын рәсем аша җиткерә белүне ныгыту. Балаларны милли киемнәр, халык мәдәнияте үрнәкләре белән таныштыруны дәвам итү. |

| | | |
|---|---|---|
| 3.12.-7.12. | **Салкын кыш. Кышкы уеннар.**<br>1. Кышкы табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзаллаулары, бәйләнешле сөйләмен үстерү<br>3. Кыш турында белемнәрен тирәнәйтү, авазларның дөрес әйтелешен ныгыту.<br>4. Туган як табигатендәге үзгәрешләргә карата кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>5. Кайбер әйберләрнең бер халәттән икенче хәләткә керүен тәҗрибә ясау ысулы белән күзәтеп, балаларның белемнәрен тирәнәйтү. | 1. **ФЭМП.** Предметларны төрле юнәлештә санау. Предметларны бирелгән сан буенча исәпләү. Кәгазь битендә ориентлашу. Озынлык һәм калынлык . Максат: Исәпне төрле юнәлештә алып барып булганлыгын аңлату, сулдан уңга, уңнан сулга, өстән аска, астан өскә, предметларны тугыз саны кысаларында бирелгән сан буенча санарга өйрәтү, предметларның саны һәм аларның пространствода урнашулары арасындагы бәйләнешне аңлату, предметларның озынлыклары һәм калнлыклары үзгәрүне күрергә өйрәтү һәм балаларның үзләренә дә бу сыйфатларны үзгәртү буенча күнекмәләр эшләтү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Тәҗрибә: Бер халәтнең икенче хәлгә күчүе. Максат: Туган як  табигатендәге үзгәрешләргә карата кызыксынучанлык тәрбияләү. Кайбер әйберләрнең бер халәттән икенче халәткә керүен сынап карау юлы белән балаларның белемнәрен тирәнәйтү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү**. Кышкы уеннар рәсеме буенча хикәя төзү. Максат: Балаларда үзара дустанә мөнәсәбәт, бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү. Балаларның бәйләнешле сөйләм телен, эзлекле итеп сөйли белү сәләтен үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү**. К.Ушинский "Кыш әбинең шуклыгы". Максат: Серле табигатҗ күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту. Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтләрен үстерү. Кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын аңлату.<br>5. **Рәсем**. Кышкы урман Максат: Балаларның иҗади фантазияләрен үстерү өчен, аларны төрле предметлар ярдәмендә сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Агач һәм куак сурәтләрен таякчыктан өреп ясарга өйрәтү. Нәфасәти кабул итүне үстерү: балалар игътибарын төрле ел фасылларында туган як табигате гүзәллегенә юнәлтү.<br>6. **Рәсем**. Биек һәм тәбәнәк чыршылар. Максат: төрле биеклектәге чыршылар ясарга өйрәтү, гадәти булмаган рәсем ясау ысуллары белән таныштыруны дәвам итү, якынлашып килүче бәйрәм турында әңгәмә кору. |

| | | |
|---|---|---|
| 10.12. - 14.12. | **Бездә кышлаучы кошлар.**<br>1. Балаларда кошларга карата сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.<br>3. Чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>4. Матур әдәбият аша балаларга мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.<br>5. Авазларны ныгыту буенча эшне дәвам итү. Балаларның сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүләренә ирешү, кышлаучы кошлар турында белемнәрне ныгыту.<br>6. Балаларны кошлар турында кайгыртырга, өлкәннәр ярдәмендә җимлекләр куярга өйрәтү.<br>7. Рәсемнең эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга дөрес, аңлаешлы җавап бирергә күнектерү. | 1. **ФЭМП.** Ун саны. Предметларны ун саны кысаларында санау. Озынлык буенча чагыштыру. Максат: Балаларда ун саны турындагы күзаллауны барлыкка китерү һәм унга кадәр саный белү күнекмәләрен ныгыту, саннарны исемнәрбелән килеш һәм санда килештереп санау. Бер үк төрле озынлыктагы предметларны сайлап алырга өйрәнү, парлы предметларның озынлыкларын чагыштыру, озын, кыска, озынрак, кыскарак, иң озын, тигез озынлыкта сүз тезмәләрен балалар сөйләмендә активлаштыру.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Җимнәр сибәм кошларга. Балалар бакчасы тирәли экскурсия. Максат: Балалардакошларга сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. Чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык күнекмәләрен үстерү. Кошлар турында белемнәрен баету, өлкәннәр ярдәмендә җимлекләр куярга өйрәтү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Кошлар килгән җимлеккә рәсемен карау. Максат: Балаларда кошларга сакчыл караш тәрбияләү, ярдәм итә белү теләген уяту. Рәсем эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга дөрес, ашыкмыйча башкалар аңларлык итеп җавап бирү күнекмәләрен үстерү. Рәсемгә карап хикәя төзергә өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Д.Гарифуллин “Песнәк”, Г.Лотфи “Балалар ярдәм итә”. Максат: Матур әдәбият аша мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү. Балаларда шигырне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре булдыру. Хәтер сәләтен үстерү.<br>5. **Рәсем.** Суык бизәкләр төшергән. Максат: Дулкынлы сызыклар, бормалы-сырмалы бөтеркәләр һәм кар бөртекләрен пумала очын җиңел һәм салмак йөртеп рәсем төшерергә күнектерү, эшчәнлек темасына карата үз хис-тойгыларыңны җиткерә белергә өйрәтү.<br>6. **Иң яхшы рәсемгә конкурс.** Кыш бабай, Дед Мороз, Санта-Клаус резиденцияләре” Максат: Балаларны бирем шартлары буенча рәсем ясарга өйрәтү.Әкияти йортлар рәсемен ясаганда, балаларның шәһәр һәм авыл биналарын ясау күнекмәләрен ныгыту. Балаларның иҗади фантазияләрен үстерү, үз эшләрен һәм башка балалар эшләрен объектив бәяләүләренә ирешү. |

| | | |
|---|---|---|
| 26.11.-30.11. | **Кыргый хайваннар**<br>1. Кыргый хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.<br>2. Уеннар һәм тирә-юнь белән танышу барышында балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>3. Кыргый хайваннар һәм аларның үзенчәлекләре турында белемнәрен ныгыту.<br>4. Балаларга хикәя төзеп сөйләргә булышлык итү, бер-берсен тыңлый белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>5. Балаларның үз теләкләре белән яттан шигырь сөйләргә булган омтылышларын, хәтер сәләтен үстерү.<br>6. Шигырьне укып аның төп идеясын аңларга, мөстәкыйль һәм шигырьгә бәйле рәвештә үз фикерен әйтә белергә өйрәтү. | 1. **ФЭМП.** Унга кадәр санау. Шартлы предмет моделе. Геометрик фигуралар . Максат: Исәпне төрле юнәлештә алып бару күнекмәләрен үстерү. Төрлечә урнашкан предметларны санарга өйрәтү. Ун санының барлыкка килүе турындагы белемнәрне ныгыту, унга кадәр санау. Шартлы предмет модельләре белән эшләү осталыгын формалаштыру, геометрик фигуралар – өчпочмак һәм турыпочмаклыкның якларының озынлыкларына бәйле рәвештә төрле булуларын күрсәтү. Сөйләм, игътибарлылык, логик фикерләүне үстерү. Тырышлыкка омтылышны үстерү, башлаган эшне ахырына кадәр җиткерүнең кирәклеген аңлату.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Зоопаркка сәяхәт. Максат: Кыргый хайваннарга карата кайгыртучанлык һәм зоопаркта үз-үзеңне тотусыйфатлары тәрбияләү. Уеннар һәм тирә-юнь белән танышу барышында балаларның бәйләнешле сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен үстерү. Кыргый хайваннар турында белемнәрен баету.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Куяннар . Рәсем буенча хикәя төзү. Максат: Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфатлары тәрбияләү. Карау өчен бирелгән рәсем турында сөйлисе килү теләген үстерү, хикәя төзеп сөйләүгә булышлык итү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Татар халык әкияте “Төлке белән Бүре”, болгар халык әкияте “Бүре аларны нигә ашаган”. Максат: Балаларда халык авыз иҗатына уңай караш, әкият аша дуслык, бердәмлек сыйфатлары тәрбияләү.әкият эчтәлеге буенча сорауларга тулы, аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү.<br>5. **Рәсем.** Яңа ел костюмы. Максат: Алдан уйланган образны гәүдәләндереп, кеше фигурасы рәсемен ясарга өйрәтүне дәвам итү. Карандашны йомшак кына басып, рәсемне өстән-өстән генә сызгалап чыгу күнекмәсен ныгыту. Иҗади омтылышларны, фантазияне, якыннарны сөендерү теләкләрен үстерү.<br>6. **Рәсем.**  Чыршы ботагы. Максат: Ылысларны ясаганда штрихлау төрләреннән файдаланырга өйрәтү.. Ботаклар юнәлешен, ылысларны, төс төсмерләрен натурадан карап ясау күнекмәләрен ныгыту. Туган як табигатенә соклану хисе уятып, әйләнә-тирә дөньяны нәфасәти кабул итүне үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 17.12.-<br>21.12. | **Йорт хайваннары һәм кошлары.**<br>1. Балаларда барлдык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. Аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү.<br>2. Балаларның бәйләнешле сөйләмен, бер-берсен тыңлый, башкаларның җавапларын тулыландыра алу сәләтен үстерү.<br>3. Рәсемнәр аша балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турындагы күзаллауларын системалаштыру, кешенең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру. | 1. **ФЭМП.** Предметлар санының урнашу рәвешенә бәйсез булуы. Максат: Балаларга предметларның саны аларның урнашу рәвешенә бәйсез булуын искә төшерү, төрлечә урнашкан төркемнәрдә предметлар санының тигез икәнен күрергә өйрәтү, предметларны киңлек һәм озынлык буенча чагыштыру. Күрсәтмә-образлы фикерләүне, игътибарлылыкны, күреп хәтердә калдыруны, күзаллауны, диалогик сөйләмне үстерү. Математика дәресләренә карата кызыксынуны үстерү, авыр хәлдә калганнарга ярдәм итәргә кирәклеген аңлату.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**.  Ишегалдында. Максат: Балаларда барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. Йорт хайваннары һәм кошлары турындагы күзаллауларын системалаштыру, кешенең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.**  Песи һәм песи балалары. Максат: Бер-береңне игүтибар белән бүлдермичә, сабыр гына тыңлау сыйфатлары тәрбияләү. Эчтәлекле рәсем буенча хикәя төзергә өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Г.Мөхәммәтшин “Ак  песи”. Максат: Балаларның иҗади күзаллауларын, фонематик ишетү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү. Балаларга үз тәҗрибәләренә таянып хикәя төзергә, үз фикерләрен аңлаешлы итеп башкаларга җиткерергә ярдәм итү.<br>5. **Рәсем.** Чыршы уенчыгы.  Максат: Балаларны ташландык материалга куллану табарга өйрәтү, пыялага бизәк төшерү үзенчәлекләре белән таныштыру. Буяулар тактасын буяуларны җилем белән кушу өчен куллануны хуплау. Уенчыкта ясалачак бизәкне үзең уйлап табарга һәм аны пыяла өслеккә төшерергә өйрәнү. Буяулар белән ясауның таныш алымнарын куллану күнекмәләрен ныгыту.<br>6. **Граттаж техникасы белән рәсем ясау.** Умка. Максат: Ю.Я.Яковлевның “Умка” әсәрен уку, рәсем ясауның яңа техникасы граттаж белән таныштыру. Илебез табигатенең күптөрлелеге, төрле климат зоналарында яшәүче хайваннар һәм үсемлекләр турындагы белемнәрне киңәйтү. Алгы, урта, ерак plандагы предметларны сурәтләгәндә композиция төзү осталыгын үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 8.01.-<br>25.01. | **Транспорт.**<br>1. Балаларда урамда игътибарлылык һәм транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәрбияләү.<br>2. Транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү, аларның исемнәрен истә калдыру, кулланылышын белү.<br>4. Юлда үз иминлеген һәм башкаларның иминлеген кайгырту һәм саклау сыйфаты тәрбияләү.<br>5. Матур әдәбият аша балаларның юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү һәм ныгыту. | 1. **ФЭМП.** Ишетеп санау. Предметларның озынлыгы һәм киңлегенә карап, аларны чагыштыру. Максат: Предметларның озынлыгы һәм киңлегенә карап, аларны чагыштырырга өйрәтү, күзләрне йомган килеш, кул чабуларны ишетеп санау, төрлечә урнашкан предметларны санарга өйрәтү.<br>Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын, игътибарлылыкны, сөйләмне, иҗади күзаллауны үстерү. Бердәмлек, бер-береңә ярдәм итәсе килү сыйфатын тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Җир өсте, һава һәм су транспорты. Максат: Балаларда урамда игътибарлылык һәм транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәрбияләү. Транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү. Транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Йөк машинасы һәм җиңел машина. Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү. Максат: Балаларның тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту, мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү. Бирелгән план буенча чагыштырып тасвирлау хикәясе төзергә өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Н.Дәүләтшин “Алпамыш шәһәргә килде”. Максат: Юлда үз иминлеген һәм башкаларның иминлеген кайгырту һәм саклау сыйфаты тәрбияләү. Матур әдәбият аша балаларның юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү һәм ныгыту.<br>5. **Рәсем.** Казлар-аккошлар. Максат: кошларның канат җилпеп очуларын киң буялыш аша җиткерә белергә өйрәтү, кошлар гәүдәсе өлешләренең чагыштырмаларын пумала белән төрлечә буяп, рәсем аша җиткерә алу күнекмәсен ныгыту.<br>6. **Рәсем.** Кышлаучы кошлар. Максат: гади карандаш белән сызгалап рәсем төшерергә, туган ягыбызда кышлаган кошларга хас үзенчәлекле билгеләрне рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү, кошлар хәрәкәтен рәсем аша җиткерү күнекмәсен ныгыту. |

| | | |
|---|---|---|
| 28.01.-<br>1.02. | **Юл йөрү кагыйдәләре.**<br>1. Балаларда урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасы тәрбияләү.<br>2. Юлларда күзәтүчәнлекне, фикерләү мөстәкыйльлеген, игътибарлылыкны үстерү.<br>3. Юл билгеләрен аера белү, юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам итү.<br>4. Балаларда юлда үз-үзеңне дөрес тоту культурасы тәрбияләү.<br>5. Велосипедта хәвефсез йөрү кагыйдәләрен өйрәнү. | 1. **ФЭМП.** Атна көннәренең эзлеклелеге. Кәгазь яссылыгында ориентлашу. Максат: Атна көннәренең эзлеклелегенә төгәллек кертү, балаларны кәгазҗ чяссылыгында ориентлашырга күнектерү, кәгазьнең өске, аскы, уң, сул кырыйларын, өске уң һәм сул, аскы уң һәм сул почмакларны табу, күрсәтелгән предметлар санын кәгазь битенең билгеле бер өлешендә тупларга, ничә, нинди предмет һәм аларны кая куярга кирәклеген өйрәтү, биш саны эчендә санау осталыгын ныгыту. Сөйләмне, күзаллауны, логик һәм образлы фикерләүне үстерү. Бәйрәмнәргә кызыксынуны, вакыт белән бәйле рәвештә үз эшчәнлегеңне оештырырга омтылуны тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче куркынычсызлык билгеләре. Максат: Балаларда урамда, җәмәгатҗ транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту кулҗтурасын тәрбияләү. Юл билгеләрен аера белү, юлда хәвефселек кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү**. Велосипед – минем дустым. Максат: велосипедта хәвефсез йөрү кагыйдәләрен өйрәтү. Балаларда юлда үз-үзеңне тоту кулҗтурасын тәрбияләү. Мөстәкыйлҗ фикер йөртә белү, коммуникатив сәләтләрен үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү**. Ш.Галиев “Светофорның өч күзе”. Максат: Шигырҗ аша светофор турындагы белемнәрен ныгыту, хәтер сәләтен үстерү. Шигырҗне яттан сәнгатҗле итеп сөйләргә өйрәтү.<br>5. **Күмер белән рәсем ясау.** Кышкы әкият. Максат: балаларны күмер белән рәсем ясау техникасы, аның сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыру. Рәсем сюҗетын һәм аны ничек сурәтләүне балаларның үзләреннән уйлатып, аларның иҗади омтылышларын көчәйтү. Сурәтләү эшчәнлегендә төрле материаллар кулланып, балаларның кызыесынучанлыкларын, белемнәрен арттыру.<br>6. **Рәсем.** Кыш бабай һәм Кар кызы. Максат: Кыш бабай һәм Кар кызының әкияти образларын рәсем аша җиткерергәөйрәтүне дәвам итү, предметларның зурлыклары буенча аермаларына, өлешләре пропорйияләренә игътибар юнәлтү. Фигураларның хәрәкәтләрен рәсемдә күрсәтү күнекмәсен ныгыту. Рәсемне тулыландырганда һәм шуның буенча хикәя төзегәндә, иҗади сәләтләр ачылуга этәрү. |

| | | |
|---|---|---|
| 4.02.-9.02. | **Хезмәт төбе – хәзинә.**<br>1. Балаларда хезмәт кешесенә, төзүче һөнәренә хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле сөйләм һәм танып белү эшчәнлеген үстерү.<br>3. Балаларның өлкәннәр хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү, төзүчеләр хезмәте белән таныштыру.<br>4. Матур әдәбият аша балаларда хезмәткә уңай сыйфатлар, ялкаулыкка тискәре караш тәрбияләү.<br>5. Хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү. | 1. **ФЭМП.** Шартлы үлчәм белән предметның буен һәм иңен үлчәү. Кәгазь битендә ориентлашу. Максат: Балаларны предметларның буен һәм иңен шартлы үлчәү алымы белән таныштыру. Кәгазь яссылыгында ориентлашу буенча күнегү уздыру. Кайда һәм күпме геометрик фигура урнаштырырга кирәклеген өйрәтү һәм шул билгеләнгән тәртипне истә калдыру буенча махсус күнегүләр башкару. Исәпләү күнекмәләрен арттыру. Игътибарлылык, логик фикерләү һәм хәтерне үстерү. Пөхтәлек, ярдәмчеллек, кунакчыллык тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән танышу**. Хезмәткә-хөрмәт. Максат: Балаларда хезмәт кешесенә, төзүче һөнәренә хөрмәт тәрбияләү. Балаларның өлкәннәр хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү, төзүчеләр хезмәте белән таныштыру.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Кем булырга? Әңгәмә. Максат: Хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү. Балаларның фикер йөртә белү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** К.Ушинский. “Иртәнге нурлар”. Максат: матур әдәбият аша балаларда хезмәткә уңай сыйфатлар, ялкаулыкка тискәре караш тәрбияләү. Балаларның хәтерен, игүтибарын, сөйләм күнекмәләрен үстерү. Әсәрнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен башкаларга аңлаешлы итеп җиткерә белергә өйрәтү.<br>5. **Рәсем .** Казлар-аккошлар. Максат: Кошларның канат җилпеп очуларын киң буялыш аша җиткерә белергә өйрәтү. Кошлар гәүдәсе өлешләренең пропорөионалж чагыштырмаларын пумала белән төрлечә буяп, рәсем аша җиткерә алу күнекмәсен ныгыту. А.Н.Толстой эшкәртүендәге “Казлар-аккошлар” рус халык әкиятенә иллюстрацияләр ясау аша матур әдәбият белән кызыксынуны арттыру.<br>6. **Рәсем.** Кышлаучы кошлар. Максат: Гади карандаш белән сызгалап рәсем төшерергә, туган ягыбызда кышлаган кошларга хас үзенчәлекле билгеләрне рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү. Кошлар хәрәкәтләрен рәсем аша җиткерү күнекмәсен ныгыту. Туган як табигатен, тереклек дөньясын күзәтүчәнлекне үстерү. Кошларга, аеруча кыш айларында, кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| 11.02-<br>15.02. | **Кунак булсаң, тыйнак бул.**<br>1. Балаларда кунаклар белән аралашу, үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен ныгыту, кешеләргә ихтирам тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле сөйләм һәм фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Кунакларга хөрмәт күрсәтү кагыйдәләрен бирү.<br>4. Кунакта үз-үзеңне тота белү сыйфатын тәрбияләү.<br>5. Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын, матур әдәбият әсәрләренә, халык авыз иҗатына карата кызыксынучанлыклар ын үстерү. | 1. **ФЭМП.** Квадрат һәм турыпочмаклык. Кәгазь бите яссылыгында ориентлашу. Предметларны капшап санау. Максат: Квадрат һәм турыпочмалыкны аеру осталыгын формалаштыру, аларның охшашлыгыг һәм аермалы якларын табарга өйрәтү, икесенең дә дүрт ягы һәм дүрт почмагы бар, якларының озынлыкларын күрсәтү, кәгазь яссылыгында күнегүләр ясау. Кәгазьнең сул, уң һәм өстәге, астагы почмакларын, шулай ук сул, уң, өс һәм ас якларын табарга өйрәтү. Предметларны капшап карап санау күнегүләрен үтәү. Биремне истә калдыру, аны кабатларга өйрәтү. Нәтиҗәләрне үрнәк белән чагыштыру, ябыштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Сүз эчендә энҗе бар. Максат: Балаларда кунаклар белән аралашу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, кешеләргә ихтирам тәрбияләү. Кунакларга хөрмәт күрсәтү кагыйдәләрен бирү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү..** В.Хайруллина. “Табын кагыйдәләре”. Максат:Балаларда күнакта үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү. Хәтер сәләтен. Игътибарлылыгын, матур әдәбият әсәрләренә, халык авыз иҗатына карата кызыксынучанлык үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Кунакка килегез миңа. Максат: савыт-саба атамаларын ачыклау, савыт-сабаларның өлешләрен атый белергә өйрәтү, балаларның танып белү активлыгын үстерү, табын әдәбе белән таныштыру, кунакчыл булырга өйрәтү.<br>5. **Рәсем.** Барыня. Максат: Балаларны рус халкының декоратив-гамәли сәнгате белән таныштыруны дәвам итү. Дымково барынясына бизәк төшерү кагыйдәләре белән таныштыру, бердәй ноткалар ясау өчен, бөтереп ишелгән кәгазь белән басарга өйрәнү. Пумала белән төрле юнәлешләрдә буяу күнекмәсен ныгыту, төрле зурлыктагы пумалалар куллану осталыгын камилләштерү.<br>6. **Рәсем.** Хохлома бизәкләре һәм татар орнаменты үрнәкләренә карап, симметрияле формада бизәкләр төзергә өйрәтүне дәвам итү, симметрияле итеп кисү күнекмәләрен ныгыту, бизәкне формада урнаштыру ысулын сайлаганда тоемлау хисен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 25.02-<br>.11.03. | **Хәрәкәттә-бәрәкәт.**<br>1. Балаларда ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык, уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Танып белү һәм мөстәкыйль фикерләү эшчәнлеген үстерү.<br>3. Үз теләкләрен башкаларныкы белән яраклаштырырга, иптәшләре алдында җаваплылык хисе тоярга өйрәтү.<br>4. Спорт төрләренә карата кызыксынучанлыкны үстерү.<br>**5.** Сөйләмдә грамматик формаларны һәм ясалма, мәгънәсе капма-каршы булган сүзләрне куллана белергә өйрәтү. | 1. **ФЭМП.** Геометрик фигуралар. Предметларның унда һәм сулда урнашуы. Максат: Турыпочмаклык һәм квадратны аеру күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү, квадрат һәм турыпочмаклыкның төп сыйфатлары турында күзаллауларны ныгыту, билгеләнгән юнәлештә хәрәкәт итү һәм адымнарны санау, төрле өлешләрдән торган предметларның формаларын тәртип буенча тикшереп өйрәнү, уку-укыту эшчәнлегенә ияләшү: олы кеше эндәшкәч, берәм-берәм генә җавап бирергә өйрәнү, башка балаларны тыңларга һәм аларның җавапларын тулыландырырга өйрәнү, уен кагыйдәләрен саклап, бозмыйча уйнарга өйрәнү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Минем яраткан спорт төре. Максат: балаларда ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык, уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү. Танып белү һәм мөстәкыйлҗ фикерләү эшчәнлеген үстерү. Үз теләкләрен башкаларныкы белән яраклаштырырга, җаваплылык хисе тоярга өйрәтү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** В.Хайруллин “Туплар” Максат: Балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.Спортның төрләренә кызыксынучанлыкны үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Универсиада. Максат: Татарстанның башкаласы Казанда булып узган Универсиада турында балаларның күзаллауларын киңәйтү, спортка багышланган әдәби әсәрләр белән танышу.<br>5. **Рәсем.** Ә безнең тәрәзәбездән Кызыл мәйдан күренә... Максат: Балаларның композицион күнекмәләрен үстерү, сурәтләрне киң яссылыкта урнаштырырга, предметларның кайда урнашуларына карап, аларның күләмнәре аермасын рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтү. Ясарга ниятләгәнне сюжет аша җиткерә белү күнекмәләрен ныгыту.<br>6. **Рәсем. Алдан уйлап рәсем ясау.** Зоопаркта нәрсә бар?. Максат: хайваннарның гәүдә формаларын, әгъзалары пропорцияләре чагыштырмасын үзең күзаллаганча алдан уйлап рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү. Композиция төзү күнекмәләрен ныгыту, төрле климат зоналары хайваннарын аера белүгә ирешү. Хайваннарны сурәтләгәндә, рәсемне тулыландырганда иҗади омтылышларын хуплау. |

| | | |
|---|---|---|
| 11.03.-16.03. | **Су – яшәү чыганагы.**<br>1. Табигатькә сак караш һәм мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлылыкларын үстерү.<br>3. Табигатьтә була торган үзгәрешләр турында балаларның күзаллауларын киңәйтү, яңгырның каян килеп чыгуын аңлату, табигатькә соклана һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү.<br>4. Яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү.<br>5. Гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү. | 1. **ФЭМП.** Предметларны үрнәк һәм әйтелгән сан буенча санау. Максат: Балаларда төрле предметларның тигез санын күрү һәм аны сөйләмдә чагылдыру осталыгын формалаштыру: бишәр, алтышар предмет һ.б. , билгеле бер сандагы предметларны үрнәк һәм әйтелгән сан буенча санап чыгу осталыгын ныгыту, төрлепредметларның тигез санын билгеләү өчен өстәмә алымыннан куллану, уң кул белән сулдан уңга таба хәрәкәт итеп, предметларны рәтләр буенча, берсе өстенә берсен урнаштыру.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Суның үзенчәлекләре. Максат: Яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү. Балаларның күзаллауларын, мөстәкыйль фикер йөртә белү сәләтен үстерү. Гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү**. Яңгыркаем яу, яу! Максат: Табигатькә сак караш һәм мәхәббәт тәрбияләү. Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлылыкларын үстерү. Табигатьтә була торган үзгәрешләр турында балаларның күзаллауларын киңәйтү, яңгырның каян килеп чыгуын аңлату. Табигатькә соклана һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Су һәм аның үзенчәлекләре. Максат: балаларда күзәтүчәнлек, фикерләү сәләтен һәм сөйләм телен үстерүне дәвам итү, күзәтүләр һәм, алган белемнәренә таяны, табышмаклар төзергә өйрәтү, фикереңне төгәл итеп әйтә белү күнекмәләрен үстерү.<br>5. **Рәсем**. Кышкы урман. Максат: Балаларны рәсем ясауның төрле техникалары белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның композиөия төзү күнекмәләрен ныгытрга, сурәтләрне предметларның кайда урнашуларына карап, аларның күләмнәре аермасын крсәтеп урнаштырырга өйрәтү.<br>6. **Рәсем**. Китап бите кыстыргычы. Максат: Балаларны Россия халыкларының декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре (городец бизәге) белән таныштыруны дәвам итү. Бизәкне озынча яссылыкта урнаштыру күнекмәсен ныгыту. Халык осталары эшләнмәләрен күреп соклана белүне үстерегә, чәчәк бәйләмнәре төсләре, формалары ярашу гүзәллеген күрергә өйрәтү. Халык иҗатына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| 18.02.-22.02. | **Батырлыкта матурлык.**<br>1. Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту, әтиләре белән горурлану хисе тәрбияләү.<br>2. Ватанны саклаучылар турындагы күзаллауларын киңәйтү, бәйләнешле сөйләм үстерү<br>3. Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату.<br>4. Илебезнең тынычлыгын саклаучы солдатларга карата патриотик хисләр тәрбияләү. | 1. **ФЭМП.** Предметларны озынлык һәм биеклек буенча чагыштыру.Максат: Төрле предметларның тигез санда икәнен һәм аны сөйләмдә чагылдыру осталыгын ныгыту, санарга тиешле предметларның санын хәтердә калдырырга өйрәтү, тигез-күбрәк-азрак алымы белән куллануны ныгыту, предметларны өч рәткә, берсе астына берсен тигез итеп кую, төрле озынлыктагы һәм биеклектәге предметларны чагыштырырга һәм төрле төрдәге зурлыклар арасында бәйләнеш урнаштырырга өйрәтү, иң озын, иң кыска, озынрак, кыскарак, биегрәк, тәбәнәгрәк сүзләренһәм гыйбарәләрен кертеп, балаларның сүзлек составын активлаштыру.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар. Максат: Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту, әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү. Ватанны саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Җ.Дәрзаман. “Солдат булам”. Максат: Илебезнең тынычлыгын саклаучы солдатларга карата патриотик хисләр тәрбияләү. Балаларның хәтерен, диалогик сөйләмнәрен үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.**Ватанны саклаучылар көне. Максат: хәрби профессия, хәрби техника атамаларын белеп истә калдыру һәм бу сүзләрне сөйләмдә кулланырга өйрәтү. Ватанны саклаучыларга карата ихтирам тәрбияләү.<br>5. **Рәсем.** Куәтле армиябез. Максат: Балаларны махсус транспорт өлешләренең чагыштырмача зурлыкларын һәм пропорөияләре чагыштырмаларын рәсемдә күрсәтеп тасвирларга өйрәтү. Сайлап алган техника предметына мөстәкыйль анализ ясау күнекмәсен ныгыту. Россия армиясенә, Ватанны саклаучы хәрбиләргә хөрмәт хисе тәрбияләү.<br>6. **Рәсем.** Хохлома подносы. Максат: Хохлома бизәкләре элементлары кулланып, түгәрәк кәгазь битендә сурәт ясарга өйрәтү, пумала белән ясауны мамык таякчыклар белән баскалау ысуллары белән аралаштырып эшләү. Гуашь, нәзек пумала белән эшләү күнекмәләрен, туган як үсемлекләре турындагы белемнәрне ныгыту. |

| | | |
|---|---|---|
| 18.03.-22.03. | **Заманча әкиятләр.**<br>1. Балаларда башкаларның фикерләрен бүлдермичә тыңлый белү, дөрес итеп аралаша белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның иҗади сөйләмен, үз тәҗрибәсеннән чыгып сөйли белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Заманча мультфильмны таный белергә, аларның эчтәлеге буенча үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү. | 1. **ФЭМП.** Төрле предметларның тигез санын исәпләү. Төрлечә урнаштырылган предметларны санау. Предметларны капшап санау. Максат: Төрле предметларның тигез санын күрү, предметларны уң кул белән сулдан уңга дөрес итеп санау һәм берсе астына берсен төгәл итеп урнаштыру, төркемнәрдәге предметларның тигез санын сөйләмдә чагылдыру осталыгын ныгыту, төрлечә урнаштырылган предметларны санау күнекмәләрен ныгыту, предметларны капшап санарга күнектерү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Винни-Пух кунакка бара – минем яраткан мультфильмым. Максат: Балаларда башкаларның фикерләрен бүлдермичә тыңлый белү, дөрес итеп аралаша белү сыйфатлары тәрбияләү. Иҗади сөйләмнәрен, үз тәҗрибәсеннән чыгып сөйли белү күнекмәләрен үстерү. Заманча мультфильмнарны таный белергә, аларның эчтәлеге буенча фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү**. “Карт белән төлке” татар халык әкияте белән танышу. Максат: әкиятнең башлам һәм бетем өлешләре турында аңлату, әкиятнең эчтәлеге буенча әңгәмә оештырып, балаларның сөйләм телен, фантазияләрен үстерү, әдәби сөйләмне баету.<br>4. **Сөйләм телен үстерү**. “Карт белән төлке” татар халык әкиятен сөйләү. Максат: балаларга әкиятне сөйләү планын төзергә ярдәм итү, сөйләм телен, фантазияләрен, әдәби сөйләмне үстерү, үз фикереңне әйтә белү күнекмәләрен үстерү, үзара дуслык хисләре тәрбитяләү.<br>5. **Рәсем.** Песиле тал ботагы. Максат: песиле тал ботагын натурадан карап ясарга өйрәнү, рәсемдә аның урнашу үзенчәлекләрен күрсәтү, тиешле төсмерләр табу өчен төсләр кушу. Төрле калынлыктагы пумалаларны куллану күнекмәләрен ныгыту. Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерү.<br>6. **Рәсем.** Чәчәкләр белән бизәлгән рам. Максат: фоторамалар һәм аларның бизәкләрен җентекләп карау, бизәү алымнарын күрсәтү, балалар ясаган үзенчәлекле эшләргә, аларның матурлыгына соклану, анализ ясау. |

| | | |
|---|---|---|
| 4.03-8.03. | **Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!**<br>1. Балаларда әниләргә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның логик фикерләү сәләтләрен, әниләргә карата игътибарлылыкларын үстерү.<br>3. Сорау-җавап тибында аралашу аша баланы, үз белемнәренә таянып, фикер йөртергә, гомумиләштерергә, аерып карарга һәм берләштерергә өйрәтү.<br>4. Балаларда шигырьнең тылсымлы юллары аша әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү. | 1. **ФЭМП.** Тавышларның саны һәм предметларны санап чыгу. Шар, куб, цилиндр. Алда, артта Максат: Балаларны бер үк вакытта тавышларны һәм предметларны санарга өйрәтү, отып алынган тавышлар һәм саналган предметлар саны арасында бәйләнеш урнаштыру. Балаларда шар, куб, цилиндр турындагы күзаллауны, зур һәм кечкенә үрнәктәге фигуралар эшләүне ныгыту, балаларны объектның алдында һәм артында урын табарга өйрәтү. гътибарны, сөйләмне, фикер йөртеп чагыштыруны һәм анализны, пространствода юнәлеш табу осталыгын үстерү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Суган утырту. Максат: Балаларда суган үстерү теләге тудыру, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү. Балаларның логик фикер йөртү күнекмәләрен үстерү. Суганның файдалы яшелчә икәне турында төшенчә бирү, суган үстерү турында белемнәрен тулыландыру.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Әни кирәк. Максат: Балаларда әниләргә карата ихтирам, хөрмәт хисе тәрпбияләү. Балаларның логик фикерләү сәләтен. Әниләргә карата игүтибарлылыкларын үстерү. Сорау-җавап тибында аралашу аша баланы булган белемнәренә таянып фикер йөртергә, гомумиләштерергә, аерып карага һәм берләштерегә өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Г.Гайсин “Әни гөлләре”,М.Мазунов “Яз килә”. Максат: шигырьгә кызыксыну уяту, ятлау теләге тудыру, хәтер сәләтен үстерү. Авазларны ачык әйтеп, сәнгатьле сөйләргә өйрәтү.<br>5. **Рәсем.** Әниемә Городец тактачыгы. Максат: Агач тактага, формасына туры китереп, Городец бизәге төшерергә өйрәтү. Балалрның композиөия ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү һәм бизәкләрнең таныш элементларын мөстәкыйль куллануларына ирешү. Якыннарының күңелләрен күрү теләге уяту, аларга игътибар тәрбияләү.<br>6. **Рәсем.** Әнием портреты. Максат: Балаларны портрет жанры белән таныштыру. Кеше йөзенә хас билгеләрне рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтүне дәвам итү. Иң кадерле һәм иң якын кеше буларак анага карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларның аңа игътибарлы, ихтирамлы булуларына ирешү. |

| | | |
|---|---|---|
| 25.03.-<br>29.03. | **Безнең канатлы дусларыбыз.**<br>1. Кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык хисе тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзаллау, тасвирлый белү сәләтен үстерү.<br>3. Кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап сыерчыкны һәм карганы танырга өйрәнү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру.<br>4. Әдәби әсәрләргә эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыру, диалогик сөйләмне үстерү. | 1. **ФЭМП.** Предметларны берничә өлешкә бүлү. Кычкырып санау, хәрәкәтләрне санау. Максат: Бөтен бер предметны тигез ике өлешкә һәм дүрт өлешкә бөкләп бүлергә өйрәтү, бүлү нәтиҗәләрен сөйләмдә белдерергә өйрәтү, бөтене ике тигез өлешкә бүлүдән аның яртысы барлыкка килүен аңлату, кычкырып санау буенча күнегүләрне үтәү, хәрәкәтләрне санарга өйрәтү, саннар турындагы белемнәрне ныгыту. Игътибарны, сөйләмне, логик фикерләүне, зирәклекне, күреп хәтердә калдыруны, күзаллауны үстерү. Тырышлык, дәрестә шөгыльләнү теләген, тыңлый белү сыйфатын тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Сыерчык белән карга яз килүгә шатлана. Максат: Кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. Балаларның күзаллау, тасвирлый белү сәләтен үстерү. Кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап сыерчыкны һәм карганы танырга өйрәтү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Г.Тукай “Карлыгач”. Максат: Әдәби әсәрләргә эмоөианалҗ мөнәсәбәт формалаштыру, диалогик сөйләмне үстерү. Игүтибар белән шигырь тыңларга өйрәтүне дәвам итү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Кошлар – безнең дусларыбыз! Максат: кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү, балаларның күзаллый, тасвирлый белү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен, иҗади мөмкинлекләрен үстерү, балаларга кошлар турында бедлешмә бирү, исемнәрен әйтергә өйрәтүне дәвам итү.<br>5. **Рәсем.** Март ишек төбендә. Максат: Балаларны дымлы кәгазҗ битендә акварель белән таныштыруны дәвам итү. Якын һәм ерак пландагы предметларны сурәтләү күнекмәсе формалаштыруны дәвам итү. Алдан уйлап эшләү күнекмәсе булдыру өчен, табигатьтә ел фасылларының үзгәреп торуы турында күзаллау формалаштыру.<br>6. **Рәсем.** Гөлләрем-чәчәкләрем. Максат: чәчәк бәйләме ясап, букет төзү күнекмәләрен ныгыту, урта полосадагы үсемлекләр дөньясы белән таныштырып, нәфасәти кабул итүне үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 1.04.-5.04. | **Без язны яратабыз.**<br>1. Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү<br>3. Максатчыл күзәтү аша балаларны язгы табигать күренешләре белән таныштыру.<br>4. Әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү.<br>5. Балаларны табигатьтә була торган үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү, рәсем буенча сөйли белүләренә ирешү. | 1. **ФЭМП.** Бөтеннең ике һәм дүрт тигез кисәккә бүленүе. Объекттан сулда һәм уңда урын табу. Максат: Балаларда, кушу юлы белән, бөтенне ике һәм дүрт тигез кисәккә бүлүне ныгыту, ярты дип ике тигез кисәкнең берсен атау күзаллавын ныгыту, квадратны һәм турыпочмаклыкны төрле ысуллар белән тигез кисәкләргә бүлгән вакытта нинди формалар барлыкка килүен билгеләргә өйрәтү, объекттан сулда һәм уңда урын табарга өйрәнү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Балалар бакчасы тирәли максатчан күзәтү. Максат: Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәрбияләү. Балаларның күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. Максатчан күзәтү аша балаларны язгы табигать күренеше белән таныштыру.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Рәсем буенча хикәя төзү “Яз”. Максат: Балаларда сөйләгәнне игүтибар белән тыңлый белү, юрауларга төгәл җавап бирә белү сыйфаты тәрбияләү. Әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру, бәйләнешле сөйләмне үстерү. Рәсем  буенча сөйли белүләренә ирешү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү. ЭРС** Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау.  Максат: Балаларда бер-берсен игътибар белән тыңлый, иптәше сөйләгәнне тулыландыра, аның эшчәнлегенә дөрес бәя бирә белү сыйфатлары тәрбияләү. Халык авыз иҗаты белән таныштыру аркылы балаларның сүзлек байлыгын, диалогик сөйләмнәрен, хәтер, иҗади уйлау сәләтләрен үстерү. Яз турында эндәшләр, тизәйткечләр өйрәнүне дәвам итү.<br>5. **Рәсем.** В.Бианкиның “Куыш” әсәре буенча. Максат: Балаларны төрле материалларның сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Корылмалар пропорцияләрен, хайваннарның үзенчәлекләрен рәсем аша җиткерә белү күнекмәләрен ныгыту.<br>**6.** **Рәсем.** Тәүге чәчәкләр. Максат: Рәсем ясаганда төрле сурәтләү материалларын куллана белү. Композиция ясау күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү. Балаларны туган якның тәүге чәчәкләре белән таныштыру. |

| | | |
|---|---|---|
| 15.04.-19.04. | **Уттан саклан.**<br>1. Ут чыгу куркынычы булган әйберләр белән сак булу сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Балаларның уй-фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлылыкны үстерү.<br>3. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышуны дәвам итү, янгын чыгу очрагында үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен ныгыту. | 1. **ФЭМП.** Ике һәм дүрт саннарының берәмлектән торган микъдари составы турында күзаллау формалаштыру, предметларны бөкләп һәм кисеп ике тигез өлешкә бүлү буенча күнегү башкару, бөтеннең өлештән зуррак, ә өлешнең бөтеннән кечерәк булуы турындагы белемнәрне ныгыту. Тәртип буенча исәпләү күнекмәләрен ныгыту, санны исәбе белән тәңгәлләштерергә өйрәтү. Чагыштыру, анализны аңда башкару операцияләрен үстерү, иҗади мөмкинлекләрне, игътибарны, сөйләмне, ныгытуга ирешү. Эшчәнлектә шөгыльләнү теләген, бер-берең турында кайгырту сыйфатын, киң күңеллелек тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Янгын куркынычсызлыгы. Максат: Ут чыгу куркынычы булган әйберләр белән сак булу сыйфаты тәрбияләү. Балаларның уй-фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлыдлыкларын үстерү. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү, янгын чыгу очрагында үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен ныгыту.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Г.Гыйльманов “Ярый әле”. Максат: Матур әдәбият аша балаларда саклык тәрбияләү. Балаларның уй-фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү, кушымчаларны дөрес ялган әйтә белү күнекмәләрен камилләштерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.**Янгыннан сак бул! Максат: балаларга янгын сүндерүчеләр һөнәре турында мәгълүмат бирү, ут, аның кеше тормышындагы әһәмияте һәм шул ук вакытта куркыныч яклары турында күзаллаулар булдыру.<br>5. **Рәсем.** Нәүрүз. Балаларны үзләре күзаллаган яз образын рәсемдә күрсәтергә өйрәтү. Кеше сынын пропорциональ сурәтләү күнекмәсен ныгыту. Табигатьтә яз көне күзәтелгән үзгәрешне күреп соклана белергә өйрәтү.<br>6. **Рәсем.** Әкияти гжель. Максат: Балаларны рус халкының декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләренең берсе-балчык савытларга гжель бизәге төшерү белән таныштыруны дәвам итү. Пумала белән төрле ысуллар кулланып эшләү күнекмәләрен ныгыту. Кәгазь тасмага гжель бизәге элементлары ясаганда, балаларның иҗади бизәү сәләтләрен формалаштыру. |

| | | |
|---|---|---|
| 29.04.-<br>3.05. | **Бүлмә гөлләре.**<br>1. Балаларда бүлмә гөлләренә карата сак караш тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле сөйләм, чагыштыра белү, фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Бүлмә гөлләрен үзләренә генә хас үзенчәлекләре буенча танып, бер-берсеннән аерырга өйрәтү, кеше тормышында аларның әһәмиятен аңлату.<br>4. Балаларда үсемлекләрне күзәтә белү сыйфаты, тирә-юньгә кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>5. Гади генә тәҗрибәләр ясап, балаларның хәтерен, игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү, халык авыз иҗатына кызыксынуларын арттыру. | 1. **ФЭМП.** Санның берәмлектән торган микъдар составы. Бөтенне ике һәм дүрт өлешкә бүлү . Максат:Бишкә кадәр булган саннарның берәмлектәен торган микъдари составы белән таныштыруны дәвам итү, балаларны предметларны үзара тигез булган ике һәм дүрт өлешкә бөкләү һәм кисү юлы белән бүлергә өйрәтү, бөтен һәм аның өлеше арасында булган бәйләнешне ачыклау.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Кояш, су, һаваның үсемлекләр өчен әһәмияте. Максат: Балаларда үсемлекләрне күзәтә белү сыйфаты, тирә-юньгә кызыксынучанлык тәрбияләү. Гади генә тәҗрибәләр ясап, балаларның хәтерен, игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү, халык авыз иҗатына кызыксынуларын арттыру. Балаларны белгән табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасында үзара бәйләнеш булуы турында нәтиҗә чыгару.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Хуш исле нәфис гөлләр. Максат: Балаларда бүлмә гөлләренә карата сак караш тәрбияләү. Бәйләнешле сөйләм, чагыштыра белү, фикерләү сәләтен үстерү. Бүлмә гөлләренең үзенә генә хас үзенчәлекләре буенча танып, бер-берсеннән аерырга өйрәтү, кеше тормышында гөлләрнең әһәмиятен аңлату.<br>**4. Сөйләм телен үстерү.** Бүлмә гөлләре. Максат: бүлмә гөлләренең матурлыгына соклану тудыру, сакчыл караш аша экологик белем бирү, өлкәннәрдән үрнәк алып, гөлләр үстерергә теләк уяту, әхлак тәрбиясен ныгыту, зурлар хезмәтен бәяләргә, ихтирам итәргә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү.<br>5. **Рәсем.** Әкияти кош. Максат: Гжель бизәкләренең яңа элементларын ясау алымнары белән таныштыру. Предмет силуэтларын гжель чәчәк бәйләмнәре белән бизәү күнекмәсен ныгыту. Силуэтларны бизәүдә балаларның иҗади активлыгын, мөстәкыйльлеген үстерү.<br>6. **Рәсем.** Төзелеш. Максат: Транспортка хас үзенчәлекләрне рәсемгә төшерергә өйрәтүне дәвам итү. Алгы һәм ерак пландагы предметларны күрсәтеп, сюжет сурәтләү күнекмәсен ныгыту. Балаларны үз рәсемнәре турында сөйләүгә этәрү. |

| | | |
|---|---|---|
| 8.04.-<br>12.04. | **Галәм киңлекләре.**<br>1. Балаларда беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын, хәтерен үстерү.<br>3. Балаларга Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту. | 1. **ФЭМП.** Тәртип буенча җидегә кадәр санау. Санның берәмлекләрдән торган составы. Максат: Тәртип саннарының мәгънәсен ачу һәм җидегә кадәр тәртип буенча санауның күнекмәләрен бирү, башка предметлар арасында предметның тәртип урынын билгеләгәндә, санау юнәлешенең әһәмиятен күрсәтү, санның берәмлекләрдән торган составы турында биш санына кадәр булган күзаллауны үстерүне дәвам итү. Танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын үстерү, тәртипкә салу, синтез, анализ, абстрактлаштыру, диалогик сөйләм, музыкаль ишетү сәләте. Бер-береңә игътибарлы мөнәсәбәт, хөрмәт, эстетик зәвык тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Уен “Планетарийга сәяхәт”. Максат: Балаларда беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү. Балаларның образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын, хәтерен үстерү. Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту.<br>3. **Рәсем.** Галәм. Максат: Балаларны сурәтләү сәнгатенең пейзаж жанры һәм аның төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Балаларда Галәм киңлекләре һәм күк җисемнәре турында күзаллау булдыру өчен, аларны бергәләп кәгазь битендә ясау.<br>4. **Рәсем.** Киләчәк машиналары. Максат: Дөньяда булмаган гаҗәеп машиналар уйлап таптырып, аның төп өлешләрен рәсемгә төшереп, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү. Карандашлар белән пөхтә итеп буярга күнектерү. Үз рәсемең турында сөйләргә өйрәтү.<br>5. **Сөйләм телен үстерү.** 12 апрель – космонавтика көне. Максат: атаклы шәхесләргә ихтирам, батырлыкка, кыюлыкка соклану хисләре тәрбияләү, яңа сүзләр исәбенә сүзлекләрен баету һәм кулланышка кертүне дәвам итү.<br>6. **Сөйләм телен үстерү.** Күктә  ни булмас!? Максат: яңа сүзләрне кулланышка кертү, алар исәбенә сүзлек байлыгын арттыру, космос турында сөйләү, атаклы шәхесләргә ихтирам, батырлыкка, кыюлыкка соклану хисләре тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| 22.04.-28.04. | **Г.Тукай иҗаты.**<br>**1.** Балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү.<br>2. Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру, әдәби әсәрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү.<br>3. Балаларга Г.Тукай әкиятләре аша әхлак тәрбиясе бирү.<br>4. Балаларда оештыру, алып баручы ролен башкару осталыгын формалаштыру, үзләренең эш-гамәлләрен, уенны алып баручы һәм башка катнашучыларның гамәлләренә яраклаштырырга өйрәтү. | 1. **ФЭМП.** Атна көннәре. Чиктәш саннарны чагыштыру. Предметларны ун саны эчендә санарга һәм башлап санарга күнектерү. Геометрик фигура модельләреннән предметлар төзү. Максат: Балаларның атна көннәре турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү, һәр көн атамасын тәртип саны һәм балалар эшчәнлегенең төгәл эчтәлеге белән бәйләргә өйрәтү, күрсәтмә материалга таянып, чиктәш саннарны чагыштырырга өйрәтү, биш һәм алты, алты һәм җиде, предметларны ун саны эчендә санарга һәм башлап санарга күнектерү, геометрик фигура модельләреннән төзелгән катлаулы формадагы предметларны анализларга һәм яңадан торгызырга өйрәтү<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты. Максат: Г.Тукай иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү. Тормыш юлы һәм иҗат юлы белән таныштыру, әдәби әсәрләрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** “Бала белән Күбәләк” сәхнәләштерү. Максат: балаларда оештыру һәм алып баручы ролен башкару осталыгын формалаштыру, үзләренең эш-гамәлләрен, уенны алып баручы һәм башка катнашучыларның гамәлләренә яраклашырга өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** З.Туфайлова “Тукай абый”. Максат: шигырьнең тылсымлы сүзләре аша шагыйрьгә карата мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү. Төп фикерне әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү.<br>5. **Рәсем.** Барлык профессияләр мөһим. Максат: Алдан уйлап куелганнарны рәсемдә җиткерә белергә, эшне эзлекле төстә алып барырга, предметларны кайда урнашуларына карап һәм зурлыклары буенча киң полосада ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>6. **Рәсем.** Маскарад. Максат: Хәрәкәтле һәм театрәлләштерелгән уеннар өчен битлекләрне мөстәкыйлж әзерләргә өйрәтү. Персонажның йөз-кыяфәтен җентекләп анализлау һәм рәсемдә күрсәтә белүләрен камилләштерү. Яңа төр эшчәнлек белән таныштыру аша балаларның иҗади сәләтләрен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 6.05.-10.05. | **Җиңү алып килде май.**<br>1. Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкны үстерү.<br>3. Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында балаларның белемнәрен арттыру.<br>4. Ватанны саклау теләген уяту, әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү.<br>5. Яңа очраган сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету. | 1. **ФЭМП.** Чиктәш саннарны чагыштыру. Озынлык буенча ун предмет арасында бәйләнеш урнаштыру. Максат: Чиктәш саннарны күрсәтмә материалга нигезләнеп чагыштыру күнекмәләрен формалаштыру, озынлык буенча ун предмет арасында бәйләнеш урнаштырырга күнектерү, кагыйдә нигезендә предметларны озынлыклары кимү тәртибендә бер рәткә тезәргә өйрәтү, атна көннәре турындагы мәгүлүматны ныгыту.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Сугыш ветераннары белән очрашу. “Бөек җиңү”. Максат: Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү. Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында белемнәрен арттыру.<br>3. **Сөйләм телен үстерү .** Э.Шарифуллина. “Минем бабай”. Максат: Балаларда патриотик хисләр, ватанга мәхәббәт тәрбияләү. Шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәләрен үстерү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** Җиңү яулаган каһарманнар. Максат: балаларның Бөек Ватан сугышы турындагы белемнәрен системалаштыру, сорауларга эзлекле, җыйнак, төгәл һәм матур итеп җавап бирә белү күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү, патриотик хисләр, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.<br>5. **Рәсем.** Кремль. Максат: Балаларны башкалабызның архитектурасы белән таныштыруны дәвам итү, казан Кремленең тарихи биналарының, һәйкәлләренең рәсемен ясарга өйрәтү. Биналарга хас үзенчәлекләрне рәсемдә күрсәтә белү күнекмәсен формалаштыру. Туган шәһәребез, аның гүзәллеге һәм бөеклеге белән горурлану хисен үстерү.<br>6. **Рәсем.** Җиңү көне. Максат: Әлеге тема белән бәйле предметларны сурәтләп, Җиңү көне турындагы үз хис-кичерешләрен мөстәкыйль җиткерә белергә өйрәтү. Сурәтне бөтен битне тутырып яки киң полосада урнаштыру күнекмәсен ныгыту. |

| | | |
|---|---|---|
| 13.05.-<br>17.05. | **Урман – җиребезнең матурлыгы, байлыгы.**<br>1. Балаларда урманга һәм аның байлыкларына сак караш тәрбияләү.<br>2. Кешеләр тарафыннан табигатьне сакларга кирәклеге турында нәтиҗә чыгара белү, логик фикер йөртә белү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларның урман, андагы тереклек турындагы белемнәрен тирәнәйтү, мул табигатьнең кеше тормышында әһәмиятен аңлату.<br>4. Кызыл китапка кергән хайван һәм үсемлекләрне кызгану, алар өчен борчылу хисләре уяту, табигатькә карата сак караш тәрбияләү.<br>5. Балаларны сирәк калган һәм югалып бара торган хайваннар, үсемлекләр турындагы китап белән таныштыру. | 1. **ФЭМП.** Алты һәм җиде, җиде һәм сигез саннарын чагыштыру.Балаларны саннарны чагыштырырга һәм ике катнаш санның кайсы һәм күпмегә бер-берсеннән зуррак яки кимрәк булуын билгеләргә өйрәтү, анализаторлар ярдәмендә санау күнекмәләрен үстерү, берсендә икенчесенә караганда бер элементка күбрәк яки азрак булган төркемнәр ясау, предметларның саны аларның зурлыгына бәйле булмавы турындагы күзаллауны ныгыту, карточкаларда сурәтләнгән формалар белән геометрик фигураларны чагыштырырга өйрәтү. Балаларның игътибарын, хәтерен, логик һәм иҗади сәләтләрен үстерү. Үзконтроль, үзанализ күнекмәләрен тәрбияләү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Урман почмагына экскурсия. Максат: Балаларда урманга һәм аның байлыкларына сак караш тәрбияләү. Кешеләр тарафыннан табигатҗне сакларга кирәклеге турында нәтиҗә чыгара белү, логик фикер йөртә белү сәләтен үстерү. Балаларның урман, андагы тереклек турындагы белемнәрен тирәнәйтү, мул табигатҗнең кеше тормышында әһәмиятен аңлату.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Камканы күзәтү. Максат: Балаларда табигатьтәге тереклек ияләренә карата сак караш тәрбияләү. Образлы күзаллау сәләтен, күзәтүчәнлекләрен, диалогик сөйләмне үстерү. Камка турында үзләренең белгәннәрен бәйләнешле итеп сөйләргә өйрәтү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү. .** Ф.Зариф “Татлы җәй”. Максат: Җәйге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзтүчәнлек һәм кызыксыну тәрбияләү. Әкиятнең эчтәлегеен сөйләргә өйрәтү, сүзлек запасын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>5. **Рәсем.** Кызыл калфак Максат: Балаларны әдәби әсәргә иллюстраөия ясарга өйрәтү. Ш.Перроның “Кызыл калфак” әкиятен укыгач туган тәэсирләрне рәсемдә күрсәтә белүгә ирешү. Төп геройларны аера белү, рәсем ясаганда аларны кәгазь битенең уртасына урнаштыру күнекмәсен үстерү. Эшләгәндә төрле материаллар кулланып, темага кызыксыну уяту.<br>6. **Рәсем.** Чебен-Чебенчек, кортлар-бөҗәкләр. Максат: Бөҗәкләр төзелешен рәсемдә күрсәтеп, балаларда күзаллау формалаштыру. Күмернең сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Төрле материаллар кулланып иҗади сурәтләү сәләтен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| 20.05.-<br>24.05. | **Чәчәкләр – тормыш яме.**<br>1. Чәчәкләргә сакчыл караш, туган як табигате өйрәнү теләге тәрбияләү.<br>2. Мөстәкыйль фикерләү, фикерне бер юнәлештә җыя белү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларның чәчәкләр турындагы белемнәрен баету, чәчәкләрне танып белергә, тасвирлап сөйләргә өйрәтү.<br>4. Балаларны язгы табигать күренешләре белән таныштыру, аларны күреп сөйләп бирергә өйрәтү. | 1. **ФЭМП.** Җиде һәм сигез, сигез һәм тугыз, тугыз һәм ун саннарын чагыштыру. Бармаклар белән капшап исәпләү. Предметлар санының алар арасындагы ераклыктан бәйсезлеге. Биеклек буенча тәртипкә салу. Максат: Балаларны саннарны чагыштырырга, ике санның кайсысы һәм күпмегә зуррак яки кечерәк булуын билгеләргә өйрәтү, бер-берсеннән бер предметка артык яки ким күплекләр җыелмасын күзалларга өйрәтү, предметларны тавыш буенча һәм капшап карап санарга күнектерү, предметларның саны аларның урнашу рәвешенә бәйсез булуын ныгыту, зурлыкларның тәртип белән урнашуы турындагы күзаллауны формалаштыру, өч предметның үлчәмнәрен үзара чагыштыру буенча күнекмәләр булдыру.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру.** Чәчәкләр – тормыш яме. Уен-викторина. Максат: Чәчәкләргә сакчыл караш, туган як табигатен өйрәнү теләген тәрбияләү. Мөстәкыйль фикерләү, фикерне бер юнәлештә җыя белү сәләтен үстерү. Балаларның чәчәкләр турындагы белемнәрен баету, чәчәкләрне танып белергә, тасвирлап сөйләргә өйрәтү.<br>3. **Рәсем.** Бака-патшабикә. Максат: Балаларны фантастик образлар рәсемен ясарга өйрәтүне дәвам итү, рәсемне төрле детальләр белән тулыландыру күнекмәсе булдыру. Сурәтне кәгазь битендә урнаштыру күнекмәсен ныгыту. Балаларны рус халык әкиятләре белән таныштырып, иҗади күзаллауларын үстерү, үз әкият образларын уйлап табуларына ирешү.<br>4. **Рәсем.** Сирень. Максат: Рәсем ясауның гадәти булмаган ысуллары белән таныштыруны дәвам итү. Рәсемдә төрлечә эшләү ысулларын бергә үреп бирү күнекмәсен формалаштыру. Бер төсне сыегайтып яки куертып төрле төсмерләрен кулланырга өйрәтү, төс тоемлауны үстерү.<br>**5.** **Сөйләм телен үстерү.** Гаҗәеп тирә-ягыбыз. Максат: балаларда тирә-яктагы матурлыкны тоя, күрә белергә теләк уяту, аларда хәтерне, кызыксынучанлыкны үстерү.<br>**6.** **Сөйләм телен үстерү.** Кеше тормышында чәчәкләр. Максат: чәчәкләрне саклау теләге уяту, аларга сак караш тәрбияләү, урман һәм бакча чәчәкләрен, билгеләре буенча танып, бер-берсеннән аера белергә өйрәтү. |

| | | |
|---|---|---|
| 27.05.-31.05. | **Алдакчы саран булма.**<br>1. Балаларда саранлыкка кире мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>2. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>3. Балаларга каршылыкларны мөстәкыйлж рәвештә чишәргә өйрәтү, хикәя геройларына дөрес бәя бирергә ярдәм итү. | 1. **ФЭМП.** Саннарның эзлеклелеге. Чиктәш саннарны чагыштыру. Тәртип буенча санау. Санау таякчыкларыннан геометрик фигуралар ясау. Максат: Саннарның билгеле бер эзлеклелеге турында күзаллауны формалаштыру, биш саны эчендә һәм тәртип буенча санауда чиктәш саннарны  чагыштыруны күнектерү, санау таякчыклары белән белемнәрне ныгыту, санның берәмлекләрдән торган составы, геометрик фигуралар. Игътибарны, сөйләмне, куелган бурычны һәм ирешү ысулларын аңлый белүне, куллар хәрәкәте координациясен үстерү.<br>2. **Әйләнә-тирә белән таныштыру**. Күркәм холык – изге юлдаш. Максат: балаларның вакыт турындагы белемнәрен системалаштыру, әдәби әсәрләр белән танышу, саннарны кабатлау, балаларга чакырылган җиргә үз вакытында барырга кирәклеген төшендерү.<br>3. **Сөйләм телен үстерү.** Н.Фәттах Велосипедлы Мөнир.  Максат: Балаларда саранлыкка кире мөнәсәбәт тәрбияләү. Биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Хикәя геройларына дөрес бәя бирергә ярдәм итү.<br>4. **Сөйләм телен үстерү.** С.Сәүбанның “Мактанчык алма” әкияте белән танышу. Максат: әкияттә автор әйтергә теләгән фикерне табарга өйрәтү, сөйләм телен, фантазияләрен баету, әдәби сөйләмне үстерү.<br>5. **Рәсем.** Сабантуй ярышлары. Максат:Балаларның алдан уйлап эшләүләренә ирешү. Ярышта катнашучыларның җитезлек, тизлек, көчлелек сыйфатларын катлаулы булмаган сюжет төзеп, рәсемдә күрсәтүгә этәрү. Сабантуй күренешләрен нәфасәти кабул итүгә юнәлтү. Таяну сызыклары буенча хәрәкәтне рәсемдә күрсәтә белүне ныгыту.<br>6. **Рәсем.** Түбәдә яшәүче Карлсон. Максат: Сурәтләү эшчәнлегенең берничә төрен яраштырып эшләргә өйрәтү. Балаларны рәсемдә гади хәрәкәтләрне сурәтләргә өйрәтү. Төрле формадагы, төстәге һәм зурлыктагы түбәләр фонын төзегәндә, балаларның мөстәкыйль эшләүләренә ирешү. |